# СОГЛАШЕНИЕ

## о сотрудничестве между Народным Советом Донецкой Народной Республики и Государственным Советом Республики Татарстан

Народный Совет Донецкой Народной Республики в лице Председателя Кузьмина Константина Александровича, действующего на основании Конституции Донецкой Народной Республики, с одной стороны, и Государственный Совет Республики Татарстан в лице Председателя Мухаметшина Фарида Хайрулловича, действующего на основании Конституции Республики Татарстан, с другой стороны, именуемые в дальнейшем «Стороны», исходя из взаимного стремления к установлению и расширению межпарламентских связей, придавая большое значение обмену опытом в сфере законотворческой деятельности, стремясь к дальнейшему укреплению традиционных отношений дружбы, взаимопонимания и сотрудничества, договорились о нижеследующем.

### Статья 1

Стороны осуществляют сотрудничество в соответствии с Конституцией Российской Федерации, федеральным законодательством, законодательством Донецкой Народной Республики и законодательством Республики Татарстан (далее – законодательство Сторон).

Сотрудничество основывается на принципах равенства, партнерства, взаимного уважения и учета интересов Сторон.

### Статья 2

Стороны развивают все формы межпарламентского сотрудничества в целях совершенствования законодательной основы для дальнейшего развития равноправных отношений Донецкой Народной Республики и Республики Татарстан в общественно-политической, социально-экономической и культурной сферах.

### Статья 3

Стороны уделяют особое внимание обмену опытом работы по следующим направлениям:

1) защита прав и свобод человека и гражданина;
2) укрепление законности и правопорядка;
3) обеспечение социально-экономического и инновационного развития территорий Сторон;
4) социальная защита населения;
5) охрана окружающей среды;
6) рациональное природопользование;

7) правовое регулирование организации местного самоуправления, а также государственной гражданской службы и муниципальной службы;

8) правовое регулирование в сфере культуры, туризма, спорта и молодежной политики;

9) поддержка отечественных товаропроизводителей.

Статья 4

Основными направлениями сотрудничества Сторон при реализации настоящего Соглашения являются:

1) совершенствование законодательства Сторон, законотворческого процесса, повышение открытости законотворческой и парламентской деятельности;

2) повышение эффективности планирования законотворческой деятельности;

3) анализ и оценка эффективности применения федерального законодательства и законодательства Сторон с целью выработки совместных предложений по их совершенствованию;

4) повышение эффективности планирования законотворческой деятельности;

5) расширение форм взаимодействия с институтами гражданского общества и органами местного самоуправления;

6) обмен опытом по формированию системы общественного контроля, организации мониторинга правоприменения федерального законодательства и законодательства Сторон;

7) иные направления сотрудничества Сторон, способствующие достижению целей настоящего Соглашения.

Статья 5

Стороны осуществляют сотрудничество в следующих формах:

1) обмен планами законотворческой деятельности, законопроектами, нормативными правовыми актами, информационными, аналитическими, методическими и иными материалами по вопросам законотворчества в Донецкой Народной Республике и Республике Татарстан, мониторинга правоприменения, организации деятельности законодательных органов;

2) обмен проектами федеральных конституционных законов и проектами федеральных законов, подготовленными Сторонами к внесению в Государственную Думу Федерального Собрания Российской Федерации;

3) содействие прохождению проектов федеральных конституционных законов и проектов федеральных законов, внесенных Сторонами в порядке законодательной инициативы в Государственную Думу Федерального Собрания Российской Федерации, в случае одобрения их концепции путем принятия решений о поддержке указанных проектов федеральных законов;

4) при необходимости создание совместных рабочих групп

по вопросам разработки проектов федеральных законов, вносимых в порядке законодательной инициативы в Государственную Думу Федерального Собрания Российской Федерации;

5) обмен материалами, подготовленными Сторонами по вопросам осуществления Сторонами мониторинга правоприменения и совершенствования федерального законодательства и законодательства Сторон, а также по иным интересующим Стороны вопросам;

6) участие представителей Сторон в парламентских слушаниях, научно-практических конференциях, семинарах, «круглых столах» и иных мероприятиях по вопросам законотворчества и парламентаризма;

7) организация совместных встреч, консультаций и переговоров (тематика, сроки и место проведения определяются по взаимному согласию Сторон), в том числе проведение деловых встреч депутатов и работников аппаратов Сторон, а также совместных заседаний комитетов и комиссий;

8) обмен опытом по обеспечению законотворческой и иной парламентской деятельности, в том числе путем организации стажировок работников аппаратов Сторон;

9) обмен опытом работы по информационно-технологическому сопровождению законотворческого процесса;

10) размещение информации о межпарламентских связях Сторон в государственных и иных средствах массовой информации, информационно-телекоммуникационной сети «Интернет»;

11) в иных формах, согласованных Сторонами и не противоречащих федеральному законодательству и законодательству Сторон.

Статья 6

Стороны в пределах своей компетенции оказывают содействие в проведении мероприятий, направленных на сохранение и развитие этнокультурной самобытности татар, проживающих в Донецкой Народной Республике.

Статья 7

Стороны, развивая межпарламентское сотрудничество, содействуют установлению и развитию непосредственного взаимодействия и деловых контактов между депутатами, депутатскими объединениями, постоянными и временными органами, создаваемыми Сторонами.

Статья 8

Контроль за исполнением настоящего Соглашения осуществляют Председатель Народного Совета Донецкой Народной Республики и Председатель Государственного Совета Республики Татарстан.

В целях реализации настоящего Соглашения каждая Сторона вправе определить лиц, ответственных за координацию взаимодействия Сторон.

Статья 9

Стороны самостоятельно финансируют деятельность своих представителей в рамках выполнения настоящего Соглашения.

Настоящее Соглашение не влечет для Сторон взаимных финансовых обязательств, связанных с его реализацией, и не является основанием для возникновения каких-либо имущественных обязательств и предъявления взаимных претензий.

Статья 10

В целях реализации настоящего Соглашения Стороны могут заключать дополнительные соглашения.

Разногласия, возникающие между Сторонами в отношении исполнения или толкования отдельных положений настоящего Соглашения, а также вопросы о внесении в него изменений разрешаются путем переговоров, консультаций между Сторонами или иным способом по согласованию Сторон.

Статья 11

Настоящее Соглашение вступает в силу со дня его подписания обеими Сторонами и действует бессрочно.

Действие настоящего Соглашения может быть прекращено по инициативе любой из Сторон со дня получения другой Стороной соответствующего уведомления.

Статья 12

Настоящее Соглашение составлено в двух экземплярах, имеющих равную юридическую силу для каждой из Сторон, на русском и татарском языках.

Совершено в городе Москве 15 декабря 2025 года.

**От Народного Совета Донецкой Народной Республики**

**Председатель Народного Совета Донецкой Народной Республики**

**_______________ К.А. Кузьмин**

**От Государственного Совета Республики Татарстан**

**Председатель Государственного Совета Республики Татарстан**

**_______________ Ф.Х.Мухаметшин**

**Донецк Халык Республикасы Халык Советы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы арасында парламентара хезмәттәшлек турында КИЛЕШҮ**

Донецк Халык Республикасы Халык Советы исеменнән Донецк Халык Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Донецк Халык Республикасы Халык Советы Рәисе Кузьмин Константин Александрович, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы исеменнән Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Мөхәммәтшин Фәрит Хәйрулла улы, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталучылар, парламентара багланышларны булдыруга һәм киңәйтүгә уртак омтылыштан чыгып, закон чыгару эшчәнлеге өлкәсендә тәҗрибә алмашуга зур әһәмият биреп, дус булу, бер-береңне аңлау һәм хезмәттәшлек итү традицион мөнәсәбәтләрен алга таба да ныгытуга омтылып, түбәндәгеләр хакында Килешү төзеделәр.

**1 статья**

Яклар хезмәттәшлекне Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Донецк Халык Республикасы һәм Татарстан Республикасы законнары (алга таба – Якларның законнары) нигезендә гамәлгә ашыралар.

Хезмәттәшлек тигезлек, партнерлык, бер-береңне ихтирам итү һәм Яклар мәнфәгатьләрен исәпкә алу принципларына нигезләнә.

**2 статья**

Яклар иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисадый һәм мәдәни өлкәләрдә Донецк Халык Республикасының һәм Татарстан Республикасының тигез хокуклы мөнәсәбәтләрен алга таба үстерү өчен законнар нигезен камилләштерү максатларында парламентара хезмәттәшлекнең барлык рәвешләрен үстерәләр.

**3 статья**

Яклар түбәндәге юнәлешләр буенча эш тәҗрибәсе алмашуга аерым игътибар бирәләр:

кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау;

законлылык һәм хокук тәртибен ныгыту;

3) Яклар территорияләренең социаль-икътисадый һәм инновацион үсешен тәэмин итү;

4) халыкны социаль яклау;

5) әйләнә-тирә мохитне саклау;

6) табигатьтән рациональ файдалану;

7) җирле үзидарәне оештыруны, шулай ук дәүләт граждан хезмәтен һәм муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу;

8) мәдәният, туризм, спорт һәм яшьләр сәясәте өлкәсендә хокукый җайга салу;

9) илебезнең товар җитештерүчеләренә ярдәм итү.

**4 статья**

Әлеге Килешүне гамәлгә ашырганда Якларның төп хезмәттәшлек юнәлешләре булып түбәндәгеләр тора:

1) Якларның законнарын, закон чыгару процессын камилләштерү, закон чыгару һәм парламент эшчәнлегенең ачыклыгын арттыру;

2) закон чыгару эшчәнлеген планлаштыру нәтиҗәлелеген арттыру;

3) федераль законнарны һәм Якларның законнарын камилләштерү буенча уртак тәкъдимнәр эшләү максатларында аларны куллану нәтиҗәлелеген анализлау һәм бәяләү;

4) граждан җәмгыяте институтлары һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек рәвешләрен киңәйтү;

5) җәмәгать контроле системасын булдыру, федераль законнарның һәм Яклар законнарының хокук куллану мониторингын оештыру буенча тәҗрибә алмашу;

6) Якларның әлеге Килешүнең максатларына ирешүгә ярдәм итә торган башка хезмәттәшлек юнәлешләре.

**5 статья**

Яклар хезмәттәшлекне түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашыралар:

1) закон чыгару эшчәнлеге планнары, закон проектлары, норматив хокукый актлар, Донецк Халык Республикасында һәм Татарстан Республикасында закон чыгару эшчәнлеге, хокук куллану мониторингы, закон чыгару органнары эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати, аналитик, методик һәм башка материаллар алмашу;

2) Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү өчен Яклар тарафыннан әзерләнгән федераль конституциячел законнар проектларын һәм федераль законнар проектларын алмашу;

3) Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына Яклар тарафыннан закон чыгару инициативасы тәртибендә кертелгән федераль конституциячел законнар проектларының һәм федераль законнар проектларының концепциясе аларны хуплау турында карарлар кабул итү юлы белән хупланган очракта, әлеге федераль конституциячел законнар проектларын һәм федераль законнар проектларын үткәрүдә ярдәм итү;

4) кирәк булганда, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертелә торган федераль законнар проектларын эшләү мәсьәләләре буенча уртак эшче төркемнәр төзү;

5) Яклар тарафыннан хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру һәм федераль законнарны, Якларның законнарын камилләштерү мәсьәләләре, шулай ук Якларны кызыксындыра торган башка мәсьәләләр буенча Яклар әзерләгән материаллар алмашу;

6) Яклар вәкилләренең парламент тыңлауларында, фәнни-гамәли конференцияләрдә, семинарларда, түгәрәк өстәлләрдә һәм закон чыгару эшчәнлеге һәм парламентаризм мәсьәләләре буенча башка чараларда катнашуы;

7) уртак очрашулар, киңәшүләр һәм сөйләшүләр оештыру (аларның тематикасы, уздыру вакыты һәм урыны Якларның уртак килешүе буенча билгеләнә), шул исәптән Яклар депутатларының һәм аппаратлары хезмәткәрләренең эшлекле очрашуларын, шулай ук комитетларның һәм комиссияләрнең берләштерелгән утырышларын үткәрү;

8) закон чыгару эшчәнлеген һәм башка парламент эшчәнлеген тәэмин итү буенча, шул исәптән Яклар аппаратлары хезмәткәрләренең стажировкаларын оештыру юлы белән дә, тәҗрибә алмашу;

9) закон чыгару процессын мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча эш тәҗрибәсен алмашу;

10) Якларның парламентара багланышлары турындагы мәгълүматны дәүләт һәм башка массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру;

11) Яклар килештергән һәм федераль законнарга һәм Яклар законнарына каршы килми торган башка рәвешләр.

**6 статья**

Яклар үз компетенцияләре кысаларында Донецк Халык Республикасында яшәүче татарларның этномәдәни үзенчәлеген саклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрүдә ярдәм күрсәтәләр.

**7 статья**

Яклар, парламентара хезмәттәшлекне үстереп, депутатлар, депутат берләшмәләре, Яклар тарафыннан төзелә торган даими һәм вакытлы органнар арасында турыдан-туры хезмәттәшлекне һәм эшлекле элемтәләрне булдыруда һәм үстерүдә ярдәм итәләр.

**8 статья**

Әлеге Килешү үтәлешен тикшереп торуны Донецк Халык Республикасы Халык Советы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе гамәлгә ашыралар.

Яклар әлеге Килешүне гамәлгә ашыру максатларында аларның хезмәттәшлеген координацияләү өчен җаваплы затларны билгеләргә хокуклы.

**9 статья**

Яклар әлеге Килешүне үтәү кысаларында үз вәкилләренең эшчәнлеген мөстәкыйль финанслыйлар.

Әлеге Килешү Яклар өчен аны гамәлгә ашыруга бәйле уртак финанс йөкләмәләренә китерми һәм нинди дә булса мөлкәти йөкләмәләр барлыкка килү, уртак дәгъвалар белдерү өчен нигез була алмый.

**10 статья**

Әлеге Килешүне гамәлгә ашыру максатларында Яклар өстәмә килешүләр төзергә мөмкин.

Әлеге Килешүне үтәүгә яисә аның аерым нигезләмәләрен аңлатуга карата Яклар арасында килеп чыга торган фикер төрлелекләре, шулай ук аңа үзгәрешләр кертү мәсьәләләре Яклар арасында сөйләшүләр, киңәшүләр юлы яисә Якларның килешүе буенча башка ысул белән хәл ителә.

**11 статья**

Әлеге Килешү ике Як тарафыннан имзаланган көннән үз көченә керә һәм чикләнмәгән вакытка гамәлдә була.

Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы теләсә кайсы Якның башлангычы буенча башка Як тиешле хәбәрне алган көннән алып туктатылырга мөмкин.

**12 статья**

Әлеге Килешү Якларның һәрберсенә бер үк юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә рус һәм татар телләрендә төзелде.

Мәскәү шәһәрендә 2025 елның 15 декабрендә имзаланды.

| | |
|---|---|
| Донецк Халык Республикасы<br>Халык Советы<br>Рәисе | Татарстан Республикасы<br>Дәүләт Советы<br>Рәисе |
| К.А. Кузьмин | Ф.Х. Мөхәммәтшин |